**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422606 с. Габишево,
ул. пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ** *РАЙОНЫ* **ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

---

**№9** **04.04.2019 г.**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлегенең хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләр башкаручы хәрби-исәп хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләр башкаручы хәрби-исәп хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен һәм хезмәтенә түләүне тәртипкә салуны тәэмин итү максатыннан һәм Россия Федерациясе оборона министрлыгының 2014 елның 23 апреленнән №255 (2016 елның 18 августы редакциясендә, 2018 елның 30 гыйнварыннан үзгәртүләр белән) “Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 5 августыннан №583” (“Россия Федерациясе хәрби частьләре һәм кораллы көчләре оешмалары гражданлык персоналы хезмәтенә түләү системасы турында Кагыйдә”, (“Россия Федерациясе хәрби частьләре һәм кораллы көчләре оешмалары гражданлык персоналы хезмәтенә түләү фондын формалаштыру һәм файдалану Тәртибе” белән бергә) карарын тормышка ашыру буенча чаралар турында” Боерыгына нигезләнеп,Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлегенең хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләр башкаручы хәрби-исәп хезмәткәрләре (алга таба – хәрби-исәп хезмәткәрләре) хезмәт хакы хезмәттәге айлык окладтан, хезмәттәге окладка хезмәттәге еллары өчен айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча премиядән, аерым климатик шартлы (район коэффициентында) җирлектә эшләү өчен түләүләрдән, календарь ел йомгаклары буенча вазифаи бурычларын намуслы башкарган өчен акчалата бүләктән тора дип билгеләргә.
2. Хәрби-исәп хезмәткәрләренең вазифаи оклады Россия Федерациясе оборона Министрлыгының 2014 елның 23 апреленнән №255 “Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 5 августыннан №583” “инспектор” дәрәҗәсе буенча” карарын тормышка ашыру буенча чаралар турында” боерыгына ярашлы төстә билгеләнә һәм 6552 сум тәшкил итә дип расларга.
3. Хәрби-исәп хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) вазифаи окладка хезмəттəге еллар өчен айлык өстəмə түбəндəге күлəмдə:

эш стажы түбəндəгечəпроцентларда

1 елдан артык5;
2 елдан артык10;
3 елдан артык15;
5 елдан артык20;
10 елдан артык30;
15 лдан артык40.

2) хезмəткə түлəүнең билгелəнгəн фонды чиклəрендə эш нəтиҗəлəре буенча премия (премия күлəме хезмəткəр эшчəнлеге күрсəткечлəреннəн чыгып билгелəнə һəм максималь күлəме чиклəнми).

Ай (квартал, ел) өчен эш кəрсəткечлəре буенча премия түлəү хезмəткə түлəү фондының бу максатларга каралган акчалар чиклəрендə башкарыла.

3) аерым климатик шартлы (район коэффициентында) җирлектə эшлəү өчен түлəүне исəплəнгəн хезмəт хакыныə гомуми суммасыннан 1,15 күлəмендə билгелəргə.

4) вазифаи бурычларны намуслы башкару өчен акчалата бүлəклəү елына 2 вазифаи окладка кадəр.

Хезмəткəргə түлəнə торган бүлəк күлəме аңа бүлəклəү түлəнүче календарь елның 1 декабренə билəгəн вазифасы буенча билгелəнгəн ике вазифаи окладтан артык була алмый, күтəрелүлəрне дə исəпкə алып, ə эштəн киткəн кешегə ел дəвамында- эштəн киткəн көненə.

4. Шуны билгелəргə:

хəрби-исəп хезмəткəрлəренең вазифаи окладлары, шулай ук айлык һəм башка түлəүлəр күлəме үстерү ягына таба тулы сумга кадəр түгəрəклəнергə тиеш.

5. Бу карарның гамəлдə булуы 2019 елның 1 гыйнварына булган хокук мөнəсəбəтлəренə караганлыкны билгелəргə.

6. Әлеге карар үтəлешенə контрольлек итүне Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советының план-бюджет һəм икътисади үсеш комиссиясенə йөклəргə.

**Башлык – Лаеш муниципаль районы**
**Габишево авыл җирлеге**
**Советы рəисе** **Р.Т.Хөсəенов**